МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**31.05.2018** **г. Казань** **№ 1500-р**

Татарстан җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 13.02.2017 ел, № 283-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 13.02.2017 ел, № 283-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.»;

1.4.4 пунктның 2 подпунктында «(http://uslugi.tatar.ru/)» сүзләрен «(http://uslugi.tatarstan.ru/)» сүзләре белән алыштырырга;

1.5 пунктта:

Түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” 25 октябрь 2001 ел, № 137-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 137-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4148 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);»;

Унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК) (Татарстан Республикасы, 1998, 15 август, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);»;

1.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – муниципаль районнардагы авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе.»;

2 бүлектә:

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы | Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать кергәннән соң утыз календарь көне эчендә күрсәтелә.<br>Җир кишәрлеге ясалырга тиешле җир кишәрлегенең урнашу схемасына № 137-ФЗ Федераль закон 3.5 статьясы 10 пункты нигезендә килештерү таләп ителсә, дәүләт хезмәте гариза кергәннән соң 45 көн эчендә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмтен күрсәтүне туктатып тору срогы каралмаган. | РФ ҖК 39.29 ст. 8, 8.1 п. |

2.5 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» графасына «гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе,» сүзләреннән соң «шул исәптән, электрон формада,» дигән сүзләрне өстәргә;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Гариза һәм аңа теркәлгән документларны гариза бирүче кәгазь форматта түбәндәге ысуллар белән тапшыра (юллый) ала:

шәхсән үзе (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат);

почта аша.»;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» графасына «гариза бирүченең аларны алу ысуллары,» сүзләреннән соң «шул исәптән, электрон формада,» сүзләрен өстәргә;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:

1) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРЮЛ) гариза бирүче булган юридик зат турында белешмә, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ);

2) Шәхси эшмәкәрләр бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРИП) гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында белешмә - ТР буенча Федераль салым идарәсенә;

3) Җир кишәрелегенә Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан (алга таба – ЕГРН) өземтә яки ЕГРНда җир кишәрлеге турында соралган мәгълүматлар булмавы турында - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча Росреестр);

Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үзе дә китерә ала, шул исәптән, мөмкинлек булса, электрон формада.

Гариза бирүченең алда күрсәтелгән документларны тапшырмавы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.

Гариза бирүчедән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарында, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында яки дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнарының ведомоствосында булган оешмаларның карамагында булган өстә

санап үтелгән документларны таләп итү тыела, №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 6 бүлегендә каралган документлар гына чыгарма булып тора.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Гариза бирүче китергән җир кишәрлегенең урнашу схемасына Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән килештерелү таләп ителә, җир кишәрлегенең № 137-ФЗ Федераль закон 3.5 статьясы 10 пунктында күрсәтелгән җирләрдән ясалуы чыгарма булып тора | № 137-ФЗ Федераль закон 3.5 ст.»; |

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында пункта 2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза һәм документлар кергән бер көн эчендә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә рәсмиләштерелә.»;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының унынчы абзацында 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;»;

3 бүлектә:

3.1 пунктның 3.1.1 подпунктына түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзацны өстәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хаталарны төзәтү.»;

3.4 пунктта:

3.4.1 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече эш башкару бүлегеннән гариза һәм документларны алганнан соң «ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында гариза үтү битен» (3нче кушымта) тутыра һәм

ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада запрослар юллый:

гариза бирүче булган юридик зат – оешма турында белешмә бирү турында, ТР буенча ФСХИдан;

гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында белешмә бирү турында - ТР буенча Федераль салым идарәсенә;

җир кишәрлегенә ЕГРНнан өземтә яки ЕГРНда җир кишәрлеге турында соралган мәгълүматлар булмавы турында белдерү язуы бирү турында - ТР буенча Росреестрга.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедурадан соң дүрт көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: белешмә (документлар) бирү турында запрослар.»;

Түбәндәге эчтәлекле 3.4.3, 3.4.4 подпунктлар өстәргә:

«3.4.3. № 137-ФЗ Федераль закон 3.5 статьясы нигезендә, җир кишәрлегенең № 137-ФЗ Федераль закон 3.5 статьясы 10 пунктында күрсәтелгән җирләрдән ясалганнарыннан тыш, Бүлек белгече гариза бирүче китергән җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерү өчен Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгына запрос юллый һәм гариза бирүченең җир кишәрлеге урнашу схемасын килештерүгә җибәрү турында белдерү кәгазен тәэмин итә.

Әлеге пункт билгеләгән процедуралар Бүлеккә җир кишәрлеген яңача бүлү турында гариза һәм аңа теркәлгән документлар кергәннән соң дүрт көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүче китергән җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерү турында юлланган запрос, гариза бирүченең җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерүгә җибәрүе турында белдерү кәгазе.

3.4.4. Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы белгечләре законнарда билгеләнгән срокта 3.4.3 пунктта күрсәтелгән запрос нигезендә җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерү турында яисә аны килештерүдән баш тарту турында белдерү кәгазе бирәләр.

Процедура нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән запрос нәтиҗәсе булган җир кишәрлегенең урнашу схемасын килештерү турында яисә аны килештерүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.»;

3.5 пунктның 3.5.1 подпунктындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пункты нигезендә соралган белешмәләр (документлар), шулай ук, әлеге Регламентның 3.4.3 пунктта күрсәтелгән запрос нигезендә гариза бирүче тапшырган җир кишәрлегенең урнашу схемасын

килештерү буенча Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы белдерү кәгазьләре алынганнан соң, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:»;

3.10 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хаталарны төзәтү.»;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирүченең җирләрне һәм җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында килешүдә яки җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карарында техник хатаны төзәтү буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаның төзәтелүенә нигез булып тора.»;

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары**

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куя торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен тикшереп тору юлы белән тормышка ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә тормышка ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәге тикшерүләр тора:

эш башкаруны алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча).

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куя торган башка норматив хокукый актлар таләпләренең бозылуы алдарак ачыкланган булып, аларның төзәтелгәнлеген тикшерү өчен кирәк булганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре аркасында гариза бирүчеләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуы турында шикаятьләр булганда.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү**

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлыкның карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә, Министрлыкның дәүләт хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затыннан яисә дәүләт хезмәткәреннән зарланып Министрлыкка шикаять бирергә хокуклы.

Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы һәм тәртибе бозылганда;

9) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең туктатылуы федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда күздә тотылмаган булып та, ул туктатылса.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш::

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда күрсәтелгән шартларны раслый торган документлар теркәлә ала. Бу очракта теркәләгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять карап тикшерү вакыты – аны регистрацияләгәннән соң 15 көн. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.»;

Административ регламентка 4нче кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 15 подпункт белән тулыландырырга:

«15) Җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында гаризага теркәлгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән килештерелмәгән, җир кишәрлегенең № 137-ФЗ Федераль закон 3.5 статьясы 10 пунктында күрсәтелгән җирләрдән ясалуы чыгарма булып тора.»;

Административ регламентка 5нче кушымтаны яңа теркәлгән редакциядә бәян итәргә;


Административ регламентка кушымтада (белешмәлек) «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Галиев Артур Ирек улы | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсе башлыгы<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | 221-40-89 | |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru» |

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы милкендәге
җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм
шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңача
бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына
5 нче кушымта

## Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы



Идарә башлыгы

Җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проектын яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар проектын килештерә.
2 көн

Килештерелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар проекты

Бүлек белгече

Килештерелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проектын яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар проектын Хокук идарәсенә юллый.
2 көн

Хокук идарәсенә юлланган җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар проекты

Хокук идарәсе белгече

Җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектына яки килешү төзүгә ризалык турында хат проектына яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза ясый (шул исәптән коррупциягә каршы)
3 көн

Бәяләмә проекты (кимчелекләр булганда), килештерелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Хокук идарәсе башлыгы

Бәяләмәгә имза куя яки җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә баш тарту турында карар проекты килештерә
3 көн

Килештерелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Кул куелган бәяләмә

Бүлек белгече

Хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрне төзәтә, җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен хокук идарәсенә юллый.

Килештерү өчен хокук идарәсенә юлланган җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә баш тарту турында карар

Хокук идарәсе башлыгы

Җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә баш тарту турында карар проектын килештерә

Килештерелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Бүлек белгече

Җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә баш тарту турында карар проектын имза кую өчен министрлның беренче урынбасарына җибәрә.

Килештерелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Министрның беренче урынбасары

Җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектына яки килешү төзүгә ризалык турында хат проектына яисә баш тарту турында карар проектына имза куя һәм регистрация өчен эш башкару бүлегенә җибәрә.

Имза куелган җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проекты яки килешү төзүгә ризалык турында хат проекты яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар проекты

Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече

Җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын яки килешү төзүгә ризалык турында хат проектын яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар проектын регистрацияли һәм гариза бирүчегә юллый

1 көн

Гариза бирүчегә җибәрелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карарын яки килешү төзүгә ризалык турында хатны яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар.

Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече

Гариза бирүчегә җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карарын яки килешү төзүгә ризалык турында хатны яисә килешү төзүдән баш тарту турында карарны тапшыра.

Гариза бирүчегә тапшырылган җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карарын яки килешү төзүгә ризалык турында хатны яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар.

Гариза бирүче

Кадастр эшләре башкарылуын, җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә куелуын тәэмин итә, Министрлыкка җир кишәрлегенең кадастр паспортын җибәрә (баш тартылмаган очракта)

Бүлек белгече

Килешү проекты яки килешү төзүдән баш тарту турында карар проекты әзерли, аны билгеләнгән тәртиптә килештерә һәм имза кую өчен министрның беренче урынбасарына җибәрә.

16 көн

Министрның беренче урынбасарына имза куярга юлланган проект

Килешү проектына яки килешү төзүдән баш тарту турында карар проектына имза куя һәм һәм регистрация өчен эш башкару һәм контроль бүлегенә җибәрә.

1 көн

Имзаланган килешү яки килешү төзүдән баш тарту турында карар проекты

Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече

Килешүне яисә килешү төзүдән баш тарту турында карарны регистрацияли һәм гариза бирүчегә юллый

1 көн

Гариза бирүчегә җибәрелгән килешү яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар

Гариза бирүчегә тапшырылган килешү яисә килешү төзүдән баш тарту турында карар